**РЕСПУБЛИКАТАРСТАН**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«06» август 2018ел Яр Чаллы № 3800

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 19 декарендәге «Кулланучылар кооперациясе оешмаларының Тукай муниципаль район үзәгеннән 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан һәм халык аз яши торган авыл җирлекләренә беренче чиратта кирәкле товарлар ташу белән бәйле чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Тукай муниципаль районы бюджетыннан субсидия биру тәртибе турында» 6061 санлы карарына узгәрешләр керту турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 20 ноябрендәге «Татарстан Республикасы район үзәкләреннән 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан һәм халык аз яши торган авыл җирлекләренә беренче чиратта кирәкле товарлар ташу белән бәйле чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә үзгәреш кертү турында» 887 нче карарын тормышка ашыру максатыннан, Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 19 декарендәге 6061 санлы карары белән расланган «Кулланучылар кооперациясе оешмаларыныц Тукай муниципаль район үзәгеннән 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан һәм халык аз яши торган авыл җирлекләренә беренче чиратта кирәкле товарлар ташу белән бәйле чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Тукай муниципаль районы бюджетыннан субсидия биру тәртибе»нә тубәндәге узгәрешләрне кертергә:

2.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2.4. Тукай муниципаль районының район үзәгеннән 11 чакрым ераклыкта урнашкан һәм халык аз яши торган авыл җирлекләренә беренче

чиратта кирәкле товарлар китерүгә бәйле чыгымнар буенча субсидияләр күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С = \frac{Р \times Н \times (100 + К_1) \times Ц}{100},$$

биредә:

С - субсидия күләме, сум;

Р - Тукай муниципаль районының район үзәгеннән 11 чакрым ераклыкта урнашкан һәм халык аз яши торган авыл җирлекләренә беренче чиратта кирәкле товарны ташуга кулланылган транспорт чараларының планлаштырылган ташу күләменнән, километрдан чыгып исәпләнгән барасы юлы;

Н - Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «Автомобиль транспортында ягулык һәм майлау материалларын тоту нормалары» методик рекомендацияләрен гамәлгә кертү турында» 2008 елның 14 мартындагы АМ-23-р санлы боерыгы нигезендә ягулык тотуның база нормасы, 100 километрга литр;

К1 - Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «Автомобиль транспортында ягулык һәм майлау материалларын тоту нормалары» методик рекомендацияләрен гамәлгә кертү турында» 2008 елның 14 мартындагы АМ-23-р санлы боерыгы нигезендә кышкы вакытта автотранспорт эше өчен ягулык тотуның база нормасын арттыру коэффициенты, процент;

Ц - субсидия бирү вакытына Тукай муниципаль районында ягулык-майлау материалларына базар бәясе, 1 литр өчен.».

2. Субсидия алу хокукына дәгъва кылучы кулланучылар кооперациясе оешмаларын сайлап алуны гамәлгә ашыручы комиссия составына (алга таба-Комиссия) (Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 19 декарендәге «Кулланучылар кооперациясе оешмаларының Тукай муниципаль район үзәгеннән 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан һәм халык аз яши торган авыл җирлекләренә беренче чиратта кирәкле товарлар ташу белән бәйле чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Тукай муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе турында» 6061 санлы карары белән расланган) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. комиссия составыннан Р. Т. Гыйззәтуллинны чыгарырга,

2.2. комиссия составына Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары Авзалов Ленар Гаяз улын кертергә.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.М. Камаев